БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_28_» __12__ 2019 ел № 392

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 30 декабрендәге 275 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декаберендәге 273 ФЗ номерлы Федераль закон (79 ст. 7 п.), «Өйдә укучы балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) компенсация түләүләрен бирүне гамәлгә ашыру турында» 2016 елның 14 июнендәге 0781 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының хаты, «2020 елга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 30 декабрендәге карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: 2020 елның 1 гыйнварыннан Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын һәр уку көненә 7 сум 70 тиен күләмендә субсидиядән һәм ата-аналар түләвеннән торган суммага кайнар ризык белән тукландыруны оештырырга.

1.2. 2.4 пуктына өстәргә: медик-психологик комиссия бәяләмәсе, ата-ананың башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең җайлаштырылган уку-укыту программалары буенча укуга күчерү турында гаризасы нигезендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны түләүсез кайнар ризык белән тукландыруны оештырырга.

1.3. Түбәндәге редакциядәге 2.6 пунктын өстәргә: өйдә белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга гомуми белем бирү оешмасы коры паек (азык-төлек җыелмасы) рәвешендә бушлай туклану бирә. Азык-төлек җыелмасының бәясе ике тапкыр түләүсез туклану бәясеннән чыгып билгеләнә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов